**СОВЕТ АЛЬДЕРМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422711, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Альдермыш, ул. Хабибуллина, 25

422711, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Әлдермеш авылы, Хабибуллина урамы, 25

тел./факс 8(84365) 79-4-03, e-mail: Alder.Vsg@tatar.ru


**КАРАР**
**30 сентябрь 2020 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 7**

**Әлдермеш авыл җирлегенең Биектау муниципаль районы Советына тапшырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү Вәкаләтләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында», 2019 елның 25 декабрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 мартындагы 5/1 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» карары белән расланган Әлдермеш авыл җирлегенең Биектау муниципаль районы Советына тапшырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү Вәкаләтләре исемлегенең 1 нче кушымтасының 2.18 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«2.18. килеп туган гадәттән тыш хәлләрне муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләргә кертү, гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чаралары уздыру һәм аларны үткәрүне оештыру турында карарлар кабул итү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Т.С.Сабиров